**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 23 16 июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июлендәге 460 номерлы

Указы) нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын, «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2001 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Югары Кәминкә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә (1нче кушымта);

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге, аларга билгеләнгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш (2 нче кушымта).

2. Кызыксынган муниципаль хезмәткәрләрне 1 пунктның 2 пунктчасында каралган исемлек белән таныштыру.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**башлыгы,Совет рәисе** **М.Н.Минһаҗев**

Югары Кәминкә авыл җирлеге
Советының 2021 елның 16
июнендәге 23 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне тәкъдим итү тәртибе билгеләнә:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан үзләренең алынган керемнәре, милек хокукындагы мөлкәте һәм үз мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр);

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм үзләренең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр).

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан (алга таба - граждан) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәр (алга таба - муниципаль хезмәткәр) тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү бурычы аларга йөкләнә, әгәр граждан биләүгә дәгъва итә торган яки муниципаль хезмәткәр били торган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 июнендәге 23 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә һәм җирле үзидарә органы вазыйфалары исемлегенә кертелгән булса (алга таба – Вазыйфалар исемлекләре).

3. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча, Вазыйфалар исемлекләрендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә тапшырыла.

4. Керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасында, Вазыйфалар исемлекләре белән каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә тәкъдим итә:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны буенча яки сайланулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук үзенең милек хокукында булган мөлкәте һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына);

б) граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукында булган мөлкәт һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына).

6. Муниципаль хезмәткәр ел саен тәкъдим итә:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата тәэмин итүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган үз керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр хисап чоры ахырына булган мәгълүматларга караганда;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында булган мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр хисап чоры азагына;

в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә әлеге алыш-

бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш ясалган чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

7. Вазыйфалар исемлегенә кертелмәгән муниципаль вазыйфасын биләүче һәм Вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 2, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

8. Әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе исеменә җирле үзидарә органының (муниципаль орган) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) тапшырыла.

9. Әгәр граждан яисә муниципаль хезмәткәр, алар тарафыннан җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгеченә) тапшырылган мәгълүматларында нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган булуын ачыклаган очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыра ала.

10. Объектив сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәткәр хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган очракта, бу факт муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиядә каралырга тиеш.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә бирелә торган белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр булып торалар, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса.

Бу белешмәләр җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенә һәм муниципаль хезмәткәрләрне вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларына, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда бүтән вазыйфаи затларга тапшырыла.

13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча, әгәр дә әлеге алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның

һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен гомуми кереминнән артып китсә, чаралар алу чыганаклары турында белешмәләр Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә законда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла, ә бу мәгълүматлар Чирмешән муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында булмаган очракта, бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына аларның запрослары буенча тапшырыла.

14. Вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләр белән эшләү кирә торган, аларны Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда таратуда яки файдалануда гаепле муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

15. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль хезмәткәр тарафыннан ел саен тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәр үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне җирле үзидарә органының (муниципаль орган) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгеч) тапшырып, Вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, бу белешмәләр аларга язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.

16. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яки белә торып ялган белешмәләр бирү очрагында, граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау яки тулы булмаган яки дөрес булмаган белешмәләр тапшыру яки үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау яки белә торып тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматларны бирү, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәттән азат итү, аларны биләп торган вазыйфадан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Югары Кәминкә авыл җирлеге
Советының 2021 елның 16
июнендәге
23 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге, аларга билгеләнгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле**

1. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфалары (муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына 1 нче кушымта), муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәре чикләрендә.

2. Аларны биләү коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары һәм алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү түбәндәгеләрне күздә тота:

хакимият вәкиленең яисә оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык функцияләрен даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләтләре нигезендә гамәлгә ашыру;

гражданнарга һәм оешмаларга муниципаль хезмәтләр күрсәтү;

контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру;

бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлү турында карарлар әзерләү һәм кабул итү, шулай ук чикләнгән ресурсны бүлү;

муниципаль милек белән идарә итү;

муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашыру йә лицензияләр һәм рөхсәтләр бирү;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**башлыгы,Совет рәисе** **М.Н.Минһаҗев**